РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Клянчеевского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Клянчеево, 422836
тел./факс 8(84377)33-4-31
ОГРН 1061672017990
ИНН/КПП 1622004620/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Келәнче авылы, 422836
тел./факс 8(84377)33-4-31
ОГРН 1061672017990
ИНН/КПП 1622004620/162201001

# КАРАР

**05 декабрь 2018 ел** **№ 11**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитетының
2017 елның 14 июнендәге “Стационар булмаган сәүдә
объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында” 3 санлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 14 июнендәге 3 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5нче бүлекнең 5.4нче пунктында:

1) 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) мөрәҗәгать итүченең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны гамәлгә ашыру яисә гамәлләрне башкару таләп итү;”;

2) түбәндәге эчтәлекле 10 пунктчасын өстәргә:

“10) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт

күрсәтүдән баш тартканда дөрес булмавы һәм (яки) булмавы күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш;";

1.2. 5нче бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 5.13, 5.14 пунктлар өстәргә:

5.13. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.14. Шикаять мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләнергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.".

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур.,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Д.А. Кадыйров